СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: : NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                                 Карар

17 сентябрь 2018 ел                                                     № 4-36

**«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы» Нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарсан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе                                                     Р.Ш.Гафиятуллин/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районының
Түбән Сон авыл җирлеге
Советының 17.09.2018 ел, №4-36
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмә

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында Нигезләмә( алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы,
«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә эшләнде.

## 1.**Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм халыкның турыдан-туры ихтыярын белдерүе нигезендә үткәрелә.
1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән сайлау хокукына ия булган кешеләр катнашырга хокуклы.
1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.
1.4. Гражданнар җыенда үзләре катнашалар һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.
1.5 Гражданнар җыены турыдан-туры халыкның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүе максатында үткәрелә.

## 2.Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:
- Күрсәтелгән торак пункт керә торган, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертелергә тиешле торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;
- җирлекнең чикләрне үзгәртү, күрсәтелгән җирлекне үзгәртеп кору вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла;
- җирлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан тормышка ашырыла торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлек кешеләренең саны 100 дән артык булса, җирлекнең вәкаләтле органын булдыру, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәлә буенча;

- җирлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан тормышка ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;
- җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округы яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;
- авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта халыкның инициативасын күрсәтү максатында җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйләнгән мәсьәләләр буенча;
- халык тыгыз урнашмаган яки барырга кыен булган урыннарда урнашкан җирлектә халык саны кимендә 100 кеше тәшкил итсә, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;
- авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен срогыннан элек
туктату мәсьәләләре буенча;
- авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Җыенны җирлек башлыгы үткәрә.

1.9. Җыенга әзерләнү һәм аны үткәрү белән бәйләнгән чыгымнар җирлек бюджеты акчасы хисабына башкарыла.

2. **Гражданнар җыенын чакыру тәртибе**

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрүдә инициативаны:
- җирлек башлыгы;
- кимендә ун кешедән торган сайлау хокукына ия, гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган (ягъни Россия Федерациясенең торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак
пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән эшкә сәләтле гражданнар) кешеләр төркеме, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе һәм федераль
законнарның халыкара килешүләре нигезендә хокукларга ия булучы чит ил гражданнары.

2.2. Торак пункт кешеләренең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яки инициатив төркем җыелышы беркетмәсе рәвешендә теркәлә, анда түбәндәге мәсьәләләр күрсәтелеп, гражданнар җыены үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителә:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;
гражданнар җыенын үткәрү сроклары;
гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, паспорты яки аны
алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы, имзасы яки имза куелган дата.
2.3.Җыен үткәрү инициативасын яклап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урынында теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил
итәргә, ләкин 10 нан да ким булырга тиеш түгел.
2.4. Имза кәгазьләре имзалар җыючe кешеләр тарафыннан тикшерелә, тикшерү датасы, фамилия, исем, атасының исеме, туган көне, паспорт яки аныалмаштыручы документ сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы күрсәтелә һәм җирлек башлыгына җибәрелә.

Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карары белән (2 нче кушымта), ә җирлек башлыгы инициативасы буенча – җирлек башлыгы карары белән (3 нче
кушымта) кирәкле документлар килгән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә
2.6.Җирлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы гражданнар җыенын, максатка ярашлы түгел, дип, үткәрүдән баш тартырга тиеш түгел.
2.7.Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар
җыены соравы кыска, ягъни аңа бертөрле генә җавап бирергә мөмкин булырлык итеп төзелергә тиеш.
2.8.Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе, аны күчерү җирлек Уставы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль хокук актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирлек уставында каралган тәртиптә бастырыла.
Гражданнар җыенын үткәрү турындагы җирлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карарларында гражданнар җыенына кертелә торган сорау, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәләре турында мәгълүматлар күрсәтелә.
2.9. Гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлекнең структур бүлекчәсе (башкару-боеру органы) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия торак пункт кешеләренең исемлеген төзи, гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән халыкка хәбәр итә (4 нче кушымта).

Җирлек башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.
2.9.1. Авыл халкы җыеннарның вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итә. Гражданнар җыенын билгеләү турында карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны, гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.
2.9.2. Гражданнар җыенында катнашучы һәр кеше җыен үткәрү датасына 5 көннән дә соңга калмыйча әлеге Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә гражданнар җыены турындагы материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.
2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә, җыен үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Җыенны үткәрү датасын 10 көннән дә соңга калмыйча күчерү турында Карар кабул ителергә тиеш.

3. Халык җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенда катнашучы кешеләрне теркәү өчен җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнгән, җыенда катнашучы, торак пункт кешеләре исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынынагы адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.
3.2. Җыенда катнашырга шулай ук хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган, ләкин җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнарга, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә (әгәр җыенда ткишерелә торган мәсьәләләрне хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйләнгән булса), башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә дә рөхсәт ителә. 3.3. Сайлау хокукына ия булучы торак пункт кешеләре исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта торак пункт кешесе теркәлә, һәм әлеге муниципаль берәмлек башлыгы аңа җыенда катнашырга рөхсәт бирә. 3.4. Гражданның шәхесен раслаучы (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билеты, чит ил гражданинының паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт) документ язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслау булып хезмәт итә.
3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын муниципаль берәмлек башлыгы билгели. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыены үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.
3.6. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.
Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.
3.7. Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирү уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (№5 кушымта).

3.8. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.
3.9. Халык җыены секретарьны һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны ике кешедән дә ким булмаска тиеш. Җыенның көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә халык җыены инициаторлары тарафыннан кертелгән мәсьәләләр мәҗбүри рәвештә кертелә. Әлеге мәсьәләләр беренче чиратта карала. Гражданнар Җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турындагы карар кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен җыенда катнашучы гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә.
3.10. Җыенда рәислек итүче тарафыннан халык җыены ачыла. Халык җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.
3.11. Гражданнар җыенында сәркәтип тарафыннан түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенын үткәрү датасы һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (6 нчы кушымта).
3.12. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат һәм Җыен секретаре тарафыннан имзалана һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

4. Халык җыены карарлары

4.1. Гражданнар Җыенының карары кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен тавыш бирүче гражданнарның яртысыннан артыгы сайлау хокукына ия.
4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш (№7, 8 кушымталар).
4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр. алар арасында вәкаләтләр бүлешүгә бәйле рәвештә, җирлек уставы белән билгеләнгән.
4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә, йә суд тәртибендә дөрес түгел дип танылырга мөмкин.
4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.
4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрне турыдан-туры белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен муниципаль хокукый актны кабул итү (бастырып чыгару), җирле үзидарә органы яисә күрсәтелгән актны кабул итү

(бастырып чыгару) керә торган вазыйфаи зат өстәмә рәвештә гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

Халык җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.
4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәве законнар нигезендә җаваплылык китерә.

Приложение 1

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
1нче кушымта

ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, түбәндә кул куючылар, __________________ авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыенын 00.00 сәгатьтә үткәрү инициативасын хуплыйбыз (халык җыенын үткәрү вакыты).

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ________авыл җирлегенең _________-авылы торак пунктында түбәндәге сорау буенча: ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

| № № п/п | Фамилия, исем, отчество | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имза кую датасы | имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм ______________________________________________
(фамилия, исем, отчество, туу көне,

_________________________________________________________________
Яшәү урыны, имза җыючы затның паспорт яки аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры)

____________________
(имза, дата)

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
2нче кушымта

Проект

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы бланкында

КАРАР

_______ 20** ел №____

Мамадыш муниципаль районы___________ авыл җирлегенең __________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1., 56 статьялары,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон фвыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 20___ ел, _______, ____ сәг. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең __________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 20___ ел, _______, ____ сәг. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең __________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

3.Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
__________________________

« Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарныкабул ителгән көннән алып _ _ көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге Советы Рәисе / __________/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
Знче кушымта

Проект

Муниципаль берәмлек башлыгы бланкында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
_________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карары

Мамадыш муниципаль районы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

_______ 20** ел №____

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1., 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы _________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы _____ авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча гражданнар җыенын үткәрүне 20___ нчы елның __________ билгеләргә

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ________ авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, (үзара салымнан азат ителгән гражданнарның категорияләрен күрсәтергә), 20____ елда _____ сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
___________________

« Әйе» «Юк».

2. Әлеге карарныкабул ителгән көннән алып _ _ көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге Советы
Рәисе /__________/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Исемлек

Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең ____________ торак пунктында теркәлгән сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлеге
«___» _________________ 20___ ел

| №№ пп | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Туган елы (18 яше тулган, туган көне елы, ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Халык җыенында рәислек итүче _________ _____________________
(имза) (расшифровка)
Халык җыены секретаре _________ ______________________
(имза) (расшифровка )

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

**БЮЛЛЕТЕНЬ**

___________ Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге___________ составына керүче торак пунктта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

| | | |
|---|---|---|
| Куелган мәсьәләнең эчтәлеге яшерен тавыш бирү | «Әйе» | ☐ |
| | «ЮК» | ☐ |
| | «Икеләнде» | ☐ |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

_______________________________________________________ (Торак пункт исеме)
«___» ____________ 20__ ел 00 сәг. 00 мин. № _____ ______________________
Катнашты __________________________________________________________ кеше
(торак паунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына иягражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче
_______________________________________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе:
_____________________________________________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

КӨН ТӘРТИБЕ:

1. ______________________
2. ______________________-

Беренче сорау буенча тыңладылар:
__________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышнның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар:
1. __________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышнның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
Һәм башкалар (чыгыш ясаучылар саны буенча)…

КАРАР КАБУЛ ИТТЕЛӘР: (караның эчтәлеге)

Нәтиҗәләр: «Әйе» - ____ кеше.
«ЮК» - ____ кеше
«Икеләнде» - ____ чел.
Карар _________________________
Кабул ителде (ителмәде)
Икенче сорау буенча тыңладылар:
__________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышнның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)

һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

КАРАР КАБУЛ ИТТЕЛӘР: (эчтәлеге)

Нәтиҗәләр: «Әйе» - ____ кеше

«ЮК» - ____ кеше

«икеләнде» - ____ кеше

Карар _________________________

Кабул ителде (ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________

(имза) (расшифровка )

Гражданнар җыены сәркатибе: _________ _________________

(имза) (расшифровка )

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
7 нче кушымта

КАРАР

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
__________ авыл җирлеге составына керүче _____________
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1., 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлеге составына керүче ____________ торак пунктында ___________ 20____ гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының нәтиҗәләре турында протокол төзелде. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 20___ елда ____ сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
__1.____________________________________________________________
__2.____________________________________________________________

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнарның _ _ _ кертелгән;

халык җыенында катнашучылар саны ________ Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде: «Әйе» _____ кеше тавыш бирде;

"Юк»_____ кеше тавыш бирде; Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Мамадыш муниципаль районы __________ авыл җирлегенең ________ авылында узган гражданнар җыенын гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан

файдалану мәсьәләсе буенча җыенны узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөреслеккә туры килә, дип танырга.

1)…;

2)….

1 Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә. Башлык , Мамадыш муниципаль районы _________ авыл җирлеге Советы рәисе

Халык җыенында
рәислек итүче: __________________ /______________/
(имза) (расшифровка )

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
_________ авыл җирлеге Советы рәисе ________________ / ___________/
(имза) (расшифровка )

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар
җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
8 нче кушымта

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
_______________________________________________________________
( Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы________ авыл җирлеге ______ торак пункты)
«___» ____________ 20__ ел № _____

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
халык җыены ____________________________________________________КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:
(торак пункт исеме)

1.
2.
3.

Халык җыенында
рәислек итүче: __________________ /_____________/
(имза) (расшифровка)

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
_________ авыл җирлеге Советы рәисе ________________ / __________/
(имза) (расшифровка )